**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2023 елның «12» июленнән № 35-285

Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль хезмәт турында» нигезләмәне яңа редакциядә раслау турында» 2017 елның 30 октябрендәге 30-175 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2012 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2017 елның 30 октябрендәге 30-175 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә (2018 елның 28 августындагы 40-229 номерлы, 2018 елның 27 декабрендәге 44-259 номерлы, 2019 елның 18 апрелендәге 48-281 номерлы, 2019 елның 5 июлендәге 50-303 номерлы, 2020 елның 21 февралендәге 58-357 номерлы, 2020 елның 29 апрелендәге 60-373 номерлы, 2020 елның 4 июнендәге 61-380 номерлы, 2020 елның 29 декабрендәге 4-29 номерлы, 2021 елның 8 июлендәге 11-89 номерлы, 2022 елның 28 февралендәге 19-146 номерлы, 2023 елның 16 мартындагы 32-253 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 18.7 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга;

1.2. 18.8 пунктта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләре белән алыштырырга;

1.3. 18.10 пунктта «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга;

1.4. 18.10 пунктның 3 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга;

1.5. 18.11 пунктта «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http// novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы В.М. Козлов